| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>Глава Старomензелябашского<br>сельского поселения Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районының<br>Иске Минзэлэбаш авыл җирлеге<br>башлыгы |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел 5 ноябрь № 3

Татарстан Республикасы Сарман
муниципаль районы Иске Минзэлэбаш
авыл җирлегенең Кужак авылында
2025 елда үзара салым акчаларын кертү һәм
алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзэлэбаш авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар итәм:

1.Кужак авылы гражданнарның 2025 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне 2024 елның 14 ноябренә 14 сәгатькә Кужак мәдәният йортында билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, I төркем инвалидлар; олы яшьтәге ялгыз гражданнар; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; контракт буенча хәрби хезмәт үтүче гражданнар; өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылганнар һәм аларның гаилә әгъзалары; уку йортларының көндезге бүлекләрендә укучы студентлар; хөкем ителгәннәр; авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан (СОП, янгыннан зыян күрүчеләр) тыш, Кужак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә узара салым кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә тоту белән килешәсезме?:

1) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен җиһазларны тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау(Кужак торак пунктында лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

2) су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су коймасын тәэмин итә торган башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, халыкка су ташу һәм су бирү системаларын проектлау;

3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Кужак торак пунктында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); Кужак торак пунктының Терешкова, Совет урамнарында вак таш түшәмәсен ремонтлау (махсус техника арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, вак таш ташу һәм салу, грейдерлау)) ;
4) халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерү (Кужак торак пунктында җәйге вакытта территорияне чабу (эшләр һәм килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); бензин чапкыч һәм Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу; биек агачларны кисү ) ;
5) һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү

ӘЙЕ ЮК?»

3.Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында (http:// sarmanovo. tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башлыгы А.Н.Габдрахманов